ГЛАВА АПАСТОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АПАС МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

422350, штп. Апас, Советская урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 93 . 06/12/2022

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Шәмбалыкчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2018 елның 24 августындагы 175 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә , «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 16 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 һәм 46 статьялары нигезендә һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына таянып карар бирәм:

1.Гавами тыңлауларына түбәндәгеләрне чыгарырга

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Шәмбалыкчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты;

2.Шәмбалыкчы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлауларны билгеләргә һәм 2023 елның 14 гыйнварында

10.00 сәгатьтә Ябалак авылында (Ябалак авылы, Һ. Такташ урамы, 28 нче йорт)ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышларын үткәрергә;

2023 елның 14 гыйнварында 10.30 сәгатьтә Шәмбалыкчы авылында (Шәмбалыкчы авылы, Г. Тукай урамы, 15 нче йорт);

2023 елның 14 гыйнварында 11.30 сәгатьтә Түбән Биябаш авылында (Түбән Биябаш авылы, Г. Тукай урамы, 20 йорт);

2023 елның 14 гыйнварында 12.00 сәгатьтә Урта Биябаш авылында (Урта Биябаш авылы, Островский ур., 42 нче йорт-авыл клубы) .

3. ПЗЗга үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрүне Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Шәмбалыкчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектларын әзерләү комиссиясенә (алга таба – оештыру комитеты)йөкләргә

4. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2014 елның 24 августындагы 175 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының Апас муниципаль районы » муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә гавами тыңлаулар уздырырга.

5.2022 елның 7 декабреннән 2022 елның 14 гыйнварына кадәр Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен үзгәрешләре проекты буенча экспозиция оештырырга һәм эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, шимбә көнне 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр Шәмбалыкчы авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында, Ябалаково авылы, Х.Такташ урамы, 28 йорт адресы буенча экспозиция карарга вакыт билгеләргә.

6. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://apastovo.tatarstan.ru/rus/apastovo1.htm).

7.Оештыру комитетына экспозиция эшләү чорында килүчеләр өчен консультацияләр оештырырга.

8. Оештыру комитетына гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне 2022 елның 7 декабреннән 2023 елның 13 гыйнварына кадәр шул көнне дә кертеп кабул итәргә.

1) гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышын яисә җыелышларын уздыру барышында язма яисә телдән рәвештә;

2) гавами тыңлауларның оештыру комитеты адресына язма рәвештә (җирлекнең apas.org@tatar.ru электрон почтасы һәм 422350 почта адресы буенча, Татарстан Республикасы, Апас районы, Апас штп., Совет ур., 2 й);

3) проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу юлы белән.

9. Муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен муниципаль берәмлек уставында билгеләнгән тәртиптә гавами тыңлаулар турында хәбәрнамә бастырып чыгару.

**Район Башлыгы** **А.Г. Җиһаншин**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ ОТДЕЛ